**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КИРОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

423747, Киров авылы,
Киров урамы, 52 йорт.
тел.факс.: (85552) 3-44-47
e-mail: kirov.sp@yandex.ru

**ГЛАВА КИРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

423747, пос. совхоз им. Кирова,
ул. Кирова, дом 52.
тел.факс.: (85552) 3-44-47
e-mail: kirov.sp@yandex.ru

**КАРАР**
№ 1

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
02.11.2020

Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлегенең Киров һәм Олы Имән авылларында гражданнарның үзара салым акчасын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында.

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, "Киров авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге Уставының 25.1 статьясы нигезендә Актаныш муниципаль районы, Киров авыл җирлеге Башлыгы:

**Карар бирә:**

1. Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге территориясендә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын уздыруны 2020 нчы елның 13 ноябренә билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Сез җирлектә булган түбәндә күрсәтелгән мәсьәләләрне:
Атомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:
- юлларны карап тоту, төзекләндерү, щебень, ком салу, кардан чистарту, тигезләү;

Ритуаль хезмәтләрне оештыру һәм күмү урыннарын карап тоту:
- Киров һәм Олы Имән авылларындагы зиратларны документлаштыру, агачлар кисү, территорияне төзекләндерү;

Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру:
- физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт, массакүләм чаралар оештыру һәм уздыру;

Җирлек территориясендә төзекләндерү эшләрен оештыру;
- спорт мәйданчыгы территориясен койма белән әйләндереп алу;
- авыл җирлеге территориясендәге агачларны кисү;
- хуҗасыз йортларны һәм биналарны бетерү;
- урам исемнәре һәм йорт номерлары белән күрсәткечләр урнаштыру;
- урам утларын урнаштыру, карап тору;

Җирлек чикләрендә халыкны су белән тәэмин итүне оештыру:
- су белән тәэмин итү системасын төзекләндерү, карап тору, лицензияләү;
- янгын гидрантлары урнаштыруны

хәл иту максатыннан Киров авыл җирлегендә теркәлгән, көндезге формада белем алучы студентлар, 1 төркем инвалидлар һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан кала 18 яше тулган һәр кешедән 2021 елда 1000 (бер мен) сумнан бер тапкыр максатчан җыем җыярга ризамы?"

**"ӘЙЕ"** **"ЮК"**

3. Халык җыенын түбәндәге адреслар буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Киров авылы, Киров урамы, 39 йорт, Татарстан Республикасы, Актаныш районы, Олы Имән авылы, 1 Май урамы, 33 йорт.

4. Халык җыенын оештыручы итеп Актаныш муниципаль районы Киров авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны Киров авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында игълан итәргә.

6. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы И.Ф.Гаянов